Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Түбән Мактама бистә  башкарма комитеты

КАРАР

№ 4 26 март  2020 ел

Территорияне ызанлау
проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планировка структурасы элементларын бүлеп бирү максатларында, 2020елның 04 февралендәге 791и номерлы Әлмәт муниципаль районының Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча комиссия бәяләмәсе нигезендә,

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Абдрахманов Рамил Айрат улына һәм Садыйкова Рима Әнвәр кызына үз акчалары хисабына Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Түбән Мактама ш.т.б., Әхмәтов ур., 12 җ/к, 14 җ/к адресы буенча урнашкан 16:45:070124:199, 16:45:070124:219 кадастр номерлы җир кишәрлекләре чикләрен үзгәртү өлешендә территорияне ызанлау проектын әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә.
2. Түбән Мактама бистә башкарма комитетына ызанлау проектын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Мактама бистә
башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р. Нафикова